СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

23.03.2021 Әгерҗе ш. № 7-6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында” 2016 елның 18 апрелендәге 6-6 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге карары белән үзгәрешләр кертү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “шәһәр” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 18 апрелендәге 6-6 номерлы карарына «Санлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әгерҗе районы прокуратурасының 2021 елның 17 мартындагы 02-08-01/41 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында” 2016 елның 18 апрелендәге 6-6 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында” муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пункт түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорына цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару өчен акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.».

1.2. 8 пунктның 3 пунктчасында «оешмаларының» сүзләрен «цифрлы финанс активларының, цифрлы валютаның» сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Ә.Р.Вәлиев